КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 21 июль г.Казань № 612

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль учреждениеләр күрсәтә (башкара) һәм бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлеген раслау турында» 2015 ел, 5 сентябрь, 638 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында муниципаль учреждениеләр күрсәтә (башкара) һәм бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль учреждениеләр күрсәтә (башкара) һәм бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлеген раслау турында» 2015 ел, 5 сентябрь, 638 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 30 декабрь, 1020 нче; 2016 ел, 15 апрель, 228 нче; 2016 ел, 29 декабрь, 1029 нчы; 2017 ел, 25 март, 180 нче; 2017 ел, 27 ноябрь, 914 нче; 2017 ел, 27 декабрь, 1062 нче; 2018 ел, 26 ноябрь, 1053 нче; 2018 ел, 13 декабрь, 1128 нче; 2019 ел, 28 август, 734 нче; 2019 ел, 2 ноябрь, 1002 нче; 2020 ел, 24 апрель, 323 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)

расланган Татарстан Республикасында муниципаль учреждениеләр күрсәтә (башкара) һәм бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

12 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «920000Р.16.1.КК30АА45000 | эш | мәдәни-массакүләм чаралар үткәрүне оештыру | - | - | - | - | мәдәният һәм кинематография | ХКЭТИннән сайлау»; |

17 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «920000Р.16.1.МП13АА33000 | эш | яшьләр сәясәте өлкәсендә талантлы һәм инициативалы яшьләрне үстерү системасын формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар оештыру; яшүсмерләр һәм яшьләр үзүзләрен тормышка ашыру өчен шартлар тудыру, яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең иҗади, һөнәри, интеллектуаль потенциалын үстерү | - | - | - | - | яшьләр сәясәте | ХКЭТИннән сайлау»; |

18 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «700000Р.16.1.ЖХ86АА21000 | эш | дәүләт (муниципаль) милкендәге мөлкәтне карап тоту (эксплуатацияләү) | эшнең эчтәлеге | объектларга һәм биналарга эксплуатацион-техник хезмәт күрсәтүне тәэмин итү, шулай ук әлеге объектларны һәм биналарны, җиһазларны һәм аның янындагы территорияләрне тиешле хәлдә карап тоту | эш башкару шарты | даими | торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, шәһәр төзелеше эшчәнлеге, төзелеш һәм архитектура | ХКЭТИннән сайлау»; |

28 нче пунктта:

«740000Р.16.1.ЖХ53АА35000» юлының 4 графасында «җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү» сүзләрен «җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү өчен документлар әзерләү» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «750000Р.16.1.ЖХ87АА75000 | эш | архитектура-төзелеш проектлавын гамәлгә ашыру | эш эчтәлеге | күчемсез мөлкәт объектларының проект-смета документациясен эшләү | - | - | торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, шәһәр төзелеше эшчәнлеге, төзелеш һәм архитектура | ХКЭТИннән сайлау»; |

41 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «41. «Ильинка» мәдәни-спорт комплексы» муниципаль бюджет учреждениесе | ФС41 | эш | рәсми физкультура (физкультура-сәламәтләндерү) чараларында катнашуны тәэмин итү | ярышлар үткәрү дәрәҗәсе | ХКЭТИннән сайлау | - | - | физик культура һәм спорт | ХКЭТИннән сайлау |
| | 920000Р.16.1.ФС30АА22000 | эш | гражданнарның яшәү урыны буенча физкультура-спорт юнәлешендәге дәресләр үткәрү | - | - | - | - | физик культура һәм спорт | ХКЭТИннән сайлау |
| | 920000Р.16.1.ФС42АА56000 | эш | спорт объектларына керү мөмкинлеген тәэмин итү | - | - | - | - | физик культура һәм спорт | ХКЭТИннән сайлау»; |

44 нче пунктның 9 графасында «мәдәният һәм кинематография» сүзләрен «мәдәният, кинематография, туризм» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин